**Казан шәһәре Думасының**
**2026 елның 26 февралендәге 5-6 номерлы карары**

**2025 ел өчен Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап хакында**

2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Казан шәһәре Контроль-хисап палатасының 2025 елга хисабын карап тикшергәннән соң, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

Казан шәһәре Контроль-хисап палатасының 2025 елга эшчәнлеге турындагы хисапны (кушымта) игътибарга алырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2026 елның 26 февралендәге
5-6 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре контроль-хисап палатасының**
**2025 елдагы эшчәнлеге турында**
**ХИСАП**

Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы (алга таба – Контроль-хисап палатасы) эшчәнлеге турында әлеге хисап Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә туры китереп әзерләнде.

## Эшчәнлекнең төп нәтиҗәләре

Барлыгы 2025 елда Контроль-хисап палатасы тарафыннан 42 объектка карата 15 контроль чара уздырылды, моннан тыш, бюджет акчаларын алучыда тикшерү башланды, аның нәтиҗәләре киләсе хисап чоры хисабына (2026 елга күчә торган) кертеләчәк.

Хисап чорында бюджет акчаларын куллануны тикшерү барышында 2.235.597, 8 мең сум күләмендә финанслау күләме тикшерелде. 2024 елда Казан шәһәре бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү барышында Казан шәһәре бюджет акчаларының 28 баш администраторының бюджет хисабы карап тикшерелде.

Барлыгы 1429 финанс-бюджет законнарын бозу очрагы һәм гомуми суммасы 982 818,2 мең сумлык җитмәүчелек билгеләнгән, шул исәптән:

- бюджет акчаларын максатчан кулланмау – 1 290,1 мең сум (0,1%);
- бюджет акчаларын нәтиҗәсез тоту – 67 948,3 мең сум (6,9%);
- муниципаль мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә хокук бозулар – 15 560,9 мең сум (1,6%);
- товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә закон бозулар – 268 436,0 мең сум (27,3%);
- бухгалтерлык исәбен алып бару, бухгалтерлык хисабын төзү һәм тапшыру тәртибен бозулар – 567 105,7 мең сум (57,7%);
- башка хокук бозулар һәм җитешсезлекләр – 62 477,2 мең сум (6,4%).

Шулай итеп, алдагы чорлардагы кебек үк, бухгалтерлык исәбен алып бару, бухгалтерлык хисабын төзү һәм тапшыру тәртибен бозулар, шулай ук сатып алуларны гамәлгә ашырганда хокук бозулар иң зур чагыштырма авырлыкны тәшкил итә, шул ук вакытта нәтиҗәсез чыгымнар күләме 2025 елда яртылаш кимеде, бу муниципаль учреждениеләрдә финанс дисциплинасының артуын күрсәтә.

Хисап чорында контроль чаралар нәтиҗәләре буенча муниципаль учреждениеләр тарафыннан хокук бозулар бетерелде һәм 394 651,6 мең сум, шул исәптән акча рәвешендә 7 013,2 мең сум акча бюджетка кире кайтарылды, шулай ук узган чор буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча 40 580,6 мең сумлык финанс буенча хокук бозулар бетерелде.

Йөкләнгән вәкаләтләр кысаларында Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы тарафыннан 4 муниципаль предприятие һәм акционерлык җәмгыятенә (акцияләре Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә карый) карата эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләрен формалаштыруның һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген тикшерү үткәрелде. Гомуми суммасы 96 721,7 мең сумлык 111 хокук бозу һәм җитешсезлек ачыкланды, шул исәптән:

- бухгалтерлык исәбен алып бару, бухгалтерлык хисабын төзү һәм тапшыру тәртибен бозулар – 95 533,3 мең сум (98,8 %);

- 510,4 мең сум (0,5 %) күләмендә табышның бер өлеше өстәп исәпләнде;

- муниципаль милек белән эш итү өлкәсендә 678,0 мең сумлык (0,7%) хокук бозулар.

Хисап чорында 41 149,6 мең сум күләмендәге хокук бозулар бетерелгән, шул исәптән акчалата – 510,4 мең сум, шул ук вакытта бер объект буенча контроль чарасы 2025 елның 22 декабрендә тәмамланган, шуңа күрә күрсәтмәләрне үтәү һәм хокук бозуларны бетерү срогы 2026 елга туры килә.

Тикшерүләр йомгаклары буенча тикшерү объектлары җитәкчеләренә ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм киләчәктә булдырмау буенча чаралар күрү өчен 15 күрсәтмә җибәрелгән, шуларның 12се билгеләнгән вакытта үтәлгән, 3 объект буенча үтәү срогы тәмамланмаган.

Күрсәтмәләрне үтәү нәтиҗәләре буенча барлыгы 476 381,8 мең сумлык 657 хокук бозу һәм җитешсезлек бетерелгән, 15 вазифаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

Бюджет акчаларын максатчан файдаланмаган өчен (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 15.14 статьясы), бюджет (бухгалтерлык) исәбенә, шул исәптән бюджет яки бухгалтерлык (финанс) хисабын төзүгә яки

тапшыруга карата таләпләрне тупас бозган өчен (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 15.15.6 статьясы), шулай ук бюджет йөкләмәләрен кабул итү тәртибен бозган өчен (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 15.15.10 статьясы) административ җаваплылыкка тартып 9 вазифаи затка карата административ хокук бозулар турында 10 беркетмә төзелде, 4 беркетмә буенча суд органнары тарафыннан 3 вазифаи затны 70,0 мең сумлык штраф рәвешендә җаваплылыкка тарту турында карар, калганнары буенча – кисәтү турында карар чыгарылды.

Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар йомгаклары буенча Контроль-хисап палатасы тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында башкарылган эш, контроль объектлары һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары белән үз вакытында һәм конструктив хезмәттәшлек һәм финанс дисциплинасы өлкәсендә методик ярдәм күрсәтү нәтиҗәсендә, алдагы чорлардагы кебек үк, хокук бозуларны бетерү югары дәрәҗәгә ирешелде, ул 2025 елда бетерелгән финанс ягыннан хокук бозулар суммасының 94 процентын тәшкил итте.

2025 елда Казан шәһәре прокуратурасы тикшерүе буенча 15 материал тапшырылды, аларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре прокуроры закон бозуларны бетерү турында 11 күрсәтмә бирде, гаепле кешеләрне административ җаваплылыкка тарту турында 2 карар буенча (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 7.30.1 статьясының 5 өлеше һәм 15.15.15 статьясы) кисәтү турында карар чыгарылды.

Контроль-хисап палатасы тарафыннан хисап чорында 24 эксперт-аналитик чара үткәрелде, шул исәптән: бюджет керемнәре администраторларының салым булмаган керемнәрен фаразлауга анализ ясалды, 2024 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисапка, Казан шәһәре Думасының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары проектына бәяләмәләр әзерләнде, Казан шәһәре Думасының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карарына, җир, туристлык салымнары, физик затлар мөлкәтенә салым һәм башка карарларга үзгәрешләр кертү буенча карар проектлары әзерләнде.

Бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссия утырышларында 2025 елның беренче кварталында, беренче яртыеллыгында һәм тугыз аенда Казан шәһәре бюджеты үтәлеше турындагы хисапларга бәяләмәләр бирелде.

Шуның белән бергә, Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләре буенча 2025 елда 7 муниципаль норматив – хокукый актка һәм Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 1 карарына үзгәрешләр кабул ителде һәм кертелде, мисал өчен:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 31 мартындагы 189 номерлы карары белән «Казан шәһәрен үстерү институты» МБУ тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 5 сентябрендәге 638 номерлы карары нигезендә күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеге актуальләштерелде;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 26 ноябрендәге 4127 номерлы карары белән Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертелде;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 декабрендәге 4797 номерлы карары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган хуҗалык җәмгыятьләренең (ҖЧҖ) устав капиталларындагы өлешләргә туры килә торган табыш рәвешендәге керемнәр исәпкә алынды;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 9 декабрендәге 4322 номерлы карары белән Казан шәһәренең «Авиатор» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең җир кишәрлекләреннән файдалану хокукы туктатылды.

Казан шәһәрендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру барышында контроль чаралар үткәрелгәндә, Контроль-хисап палатасы тарафыннан коррупция билгеләре, шул исәптән вазифаи затларның аффиляцияләнгән булуы һәм шәхси кызыксынуы чагылыш табарга мөмкин булган хокук бозуларга игътибар бирелә. Хисап чорында мондый фактлар ачыкланмаган.

Эшчәнлек, ачыклык һәм хәбәрдарлык турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү максатыннан Контроль-хисап палатасы тарафыннан билгеләнгән срокларда үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чаралар турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтка (www.ksp.kzn.ru), шулай ук социаль челтәргә (ВКонтакте) урнаштырыла.

Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы муниципаль учреждениеләрнең финанс-бюджет өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү (профилактикалау) чараларына аерым игътибар бирә, алар кысаларында бюджет акчаларын һәм муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле куллануны тикшерү барышында ачыклана торган бер типтагы хокук бозулар һәм кимчелекләр исемлеге ел саен актуальләштерелә һәм рәсми сайтта урнаштырыла (https://kzn.ru/meriya/ksp/tipichnye - narusheniya - i –nedostatki - vyyavlyaemye-

kontrolno-schetnoy-palatoy). Шулай ук 2025 елгы эш нәтиҗәләре буенча бер типтагы хокук бозуларга күзәтү Казан шәһәре Башкарма комитетына җибәрелде.

Казан шәһәре прокуратурасы белән үзара хезмәттәшлек турындагы килешү кысаларында Контроль-хисап палатасы белгечләре 2025 елда финанс контроле мәсьәләләре буенча прокуратура органнары үткәргән 10 тикшерүгә җәлеп ителде.

**2025 елда Контроль-хисап палатасының эшен характерлаучы төп күрсәткечләр**

| Күрсәткеч | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|
| **I. Эксперт-аналитик эшчәнлек** | |
| Эксперт-аналитик чаралар үткәрелде (берәмлек), шулардан: | 24 |
| Эксперт бәяләмәләре әзерләнде (берәмлек) | 19 |
| аналитик язмалар әзерләнде (бер.) | 5 |
| **II. Контроль-ревизия эшчәнлеге** | |
| Үткәрелгән контроль чараларның гомуми саны (бер.), шулардан | 15 |
| Казан шәһәре Мэры үтенечнамәсе нигезендә | - |
| Контроль чаралар уздырылган объектлар, барлыгы (бер.) | 42 |
| Финанс өлкәсендә ачыкланган хокук бозулар (мең сумнарда), шулардан: | 1 079 539,90 |
| бюджет акчаларыннан максатчан файдаланмау | 1 290,1 |
| бюджет акчаларын нәтиҗәсез файдалану | 67 948,3 |
| бюджет (бухгалтерлык) исәбен алып бару, бюджет (бухгалтерлык) хисабын төзү һәм тапшыру тәртибен бозулар | 662 639,0 |
| бюджетларны формалаштырганда һәм үтәгәндә хокук бозулар | 0,0 |
| муниципаль милек белән идарә иткәндә һәм аны файдалану вакытында хокук бозулар | 16 749,3 |
| муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру өлкәсендә хокук бозулар | 268 436,0 |
| башка (бүтән) хокук бозулар | 62 477,2 |
| **III. Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләре буенча эшчәнлек** | |
| Контроль-хисап палатасының күрсәтмәләре контроль объектлары җитәкчеләренә җибәрелде (берәмлекләрдә) | 15 |
| Финанс ягыннан хокук бозулар бетерелде һәм муниципаль берәмлекнең мөлкәти хәле торгызылды, барлыгы (мең сумнарда), шулардан: | 476 381,8 |
| казна учреждениеләре буенча | 435 232,2 |
| муниципаль унитар предприятиеләр буенча | 41 149,6 |
| Хисап чорында Контроль-хисап палатасын карап тотуга фактта тотылган чыгымнар (мең сумнарда) | 42 789,38 |
| Контроль-хисап палатасының контроль чаралары нәтиҗәләре буенча прокуратурага тапшырылган материаллар саны (берәмлек) | 15 |

| **Күрсәткеч** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
|---|---|
| Административ җаваплылыкка тартылган вазифаи затлар саны (кеше)/салынган штраф суммасы (мең сумнарда) | 10/70,0 |
| Дисциплинар җаваплылыкка тартылган вазифаи затлар саны (кеше) | 15 |
| Контроль-хисап палатасы материаллары буенча кузгатылган җинаять эшләре саны (бер.) | - |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**